ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.01.2025 г.Лениногорск № 6

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 8 октябрендәге 1290 номерлы «Россия Федерациясе гражданының махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм иткән затларга өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү тәртибен раслау турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Уставы белән, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 8 октябрендәге 1290 номерлы «Россия Федерациясе гражданының махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм иткән затларга өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү тәртибен раслау турында»карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктта «01.10.2024-31 дән 31.12.2024 гә кадәр» саннарын «20.01.2025 дән 30.06.2025 гәкадәр»саннарына алмаштырырга.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 8 октябрендәге 1290 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданына Россия Федерациясе кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында, махсус хәрби операциядә катнашу максатларында, контракт төзүдә ярдәм күрсәткән затларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибенә кертергә:

3 пунктта «01.10.2024 дән 31.12.2024 гә кадәр» саннарын «20.01.2025 дән 30.06.2025 гә кадәр»саннарына алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче М.Н. Гирфанов

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72